| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТАБАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТӘБӘРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2024 Тәбәрле авылы № 13

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 24.01.2023 елның 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 24.01.2023 елның 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 5 бүлекнең 5.16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә эш хакы әлеге эш бирүчедә гамәлдәге хезмәт хакы системалары, шул исәптән компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре буенча билгеләнгән хезмәт хакы күләменнән чыгып түләнә. Өстәмә эшләү өчен түләүнең конкрет күләмнәре күмәк шартнамә, килешү, локаль норматив акт яисә хезмәт шартнамәсе белән билгеләнергә мөмкин.Хезмәткәр теләге буенча, өстәмә эш хакы урынына өстәмә ял вакыты бирү белән компенсацияләнә ала, әмма Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган очраклардан тыш, өстәмә эш вакыты белән дә компенсацияләнә ала.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында: https://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга, шулай ук Татарстан

Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р.Р.Салимуллин